ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2021 ел № 7120

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, массакүләм оештырылган ихтыяри ярдәмчеләр хәрәкәтен үстерү максатларында, Россия Федерациясе Президентының 2019 елның 16 гыйнварындагы Пр-38ГСВ номерлы күрсәтмәләре исемлеген үтәү йөзеннән, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 41 статьясы, шәһәр Башкарма комитетының «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасында каралган чараларны финанслауны 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте һәм балаларны савыктыру» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2022 ел – 500 мең сум; 2023 ел – 500 мең сум; 2024 ел – 500 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2021 елның 29 октябрендәге
7120 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, датасы, номеры) | «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 27 декабрендәге 2950-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү концепциясе;<br>Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы законы;<br>Татарстан Республикасының «Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Законы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе;<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе;<br>Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге;<br>Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе |
| Программаның максаты | Милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә массакүләм оештырылган ихтыяри ярдәмчеләр хәрәкәтен үстерү |
| Программаның бурычлары | 1. Яр Чаллы шәһәрендә ихтыяри ярдәмчеләр хәрәкәтенең норматив-хокукый базасын һәм инфраструктурасын үстерү.<br>2. Халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру.<br>3. Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү. | | | | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2022-2024 еллар | | | | |
| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
| | | 2022 ел (мең сум) | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 500 | 500 | 500 | 1500 |
| | Федераль бюджет | – | – | – | – |
| | Республика бюджеты | – | – | – | – |
| | Башка чыганаклар | – | – | – | – |
| | Барлыгы | 500 | 500 | 500 | 1500 |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2024 елга чараларны тормышка ашыру хисабына планлаштырыла:<br>1. 2024 елга ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп ителгән 7 яшьтән 70 яшькә кадәрге халык өлешен әлеге яшь төркеменең гомуми санының кимендә 5% ына арттырырга.<br>2. Тормышка ашырыла торган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары, чаралар санын узган ел белән чагыштырганда ел саен кимендә 3% ка арттырырга. | | | | |
| Программаны тормышка ашыруга контроль оештыру системасы | Программа үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе гамәлгә ашыра. | | | | |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Соңгы унъеллыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) бөтен дөньяда үсеш ала. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 27 декабрендәге 2950-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү концепциясе нигезендә ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерүгә һәм таратуга булышлык итү социаль һәм яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре исәбенә кертелде.

Хәзерге дөньяда ихтыяри ярдәм (волонтерлык) әһәмиятен тикшереп, аның профилактик әһәмиятен ассызыкларга кирәк. Бүгенге көндә яшьләр арасында тискәре социаль процессларның – девиацияләрнең, социаль бүленешнең һәм тәңгәллек кризисының артуы, төгәл гражданлык позициясенең булмавы күзәтелә, мондый шартларда дәүләт, аерым алганда, шәһәр патриотик рухлы, акыллы һәм актив яшьләргә мохтаҗ. Ихтыяри ярдәм (волонтерлык), җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүдән тыш, яшьләрнең үзен социальләштерүгә һәм мобилизацияләүгә, аның гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән.

Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, риясызлык кебек әхлакый кыйммәтләрне үстерергә мөмкинлек бирә. Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) белән шөгыльләнүче гражданнар чаралар һәм акцияләр оештыру, халыкның төрле

категорияләре белән аралашу осталыгын һәм күнекмәләрен ала, бу исә аларга хезмәт базарында конкурентлыкка сәләтлелек мөмкинлеге бирә.

Хәзерге вакытта Яр Чаллы шәһәрендә 178 ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәсе исәпләнә, алар – тимурчылар отрядлары, шәһәрнең югары һәм урта махсус уку йортларының ихтыяри ярдәмчеләр отрядлары, иҗтимагый оешмалар. Ел саен шәһәрдә халыкның социаль якланмаган катламнарына ярдәм күрсәтүгә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, экологик культура формалаштыруга юнәлдерелгән 200 дән артык чара үткәрелә.

Яр Чаллы шәһәрендә бер генә зур чара да ихтыяри ярдәмчеләрне җәлеп итмичә үткәрелми.

Әмма ихтыяри ярдәмчеләр отрядларының ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү һәм аңа булышлык итү мәсьәләләре буенча үзара һәм Ихтыяри ярдәмне үстерү үзәге белән хезмәттәшлеге тотрыксыз булу сәбәпле, барлык эш күләмен дә исәпкә алып булмый. Нәтиҗәдә, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегенә системалы рәвештә булышлык итү механизмнары җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмаган, ихтыяри ярдәмчеләргә (волонтерларга) муниципаль дәрәҗәдә грант ярдәме юк, ихтыяри ярдәмчеләр кадрларын әзерләүнең, яңадан әзерләүнең һәм аларның квалификацияләрен күтәрүнең, мәгълүмат, методик материаллар алмашуның үзәкләштерелгән системасы юк.

Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм башка өлкәләрдә җәмгыятьнең социаль үсешенең мөһим факторы булып торуга бәйле рәвештә, муниципаль ярдәм системасын һәм Яр Чаллы шәһәрендә ихтыяри ярдәм өлкәсендә ведомствоара хезмәттәшлек масштабларын киңәйтү өчен шартлар булдырырга кирәк.

## 3 бүлек. Программаның тормышка ашыру сроклары күрсәтелгән төп максатлары, бурычлары

Программаны тормышка ашыру өч елга – 2022-2024 елларга исәпләнгән.

Программаның максаты – милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә массакүләм оештырылган ихтыяри ярдәмчеләр хәрәкәтен үстерү.

Программаның бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәрендә ихтыяри ярдәмчеләр хәрәкәтенең норматив-хокукый базасын һәм инфраструктурасын үстерү;

2) халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру;

3) ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү.

## 4 бүлек. Программа чаралары системасы

Программа чаралары Яр Чаллы шәһәрендә ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә ведомствоара хезмәттәшлек принциплары нигезендә билгеләнде, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендә норматив-хокукый документлар белән регламентлаштырылды.

Программа чаралары системасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләр үткәрүне үз эченә ала:

- муниципалитет дәрәҗәсендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендә закон һәм башка норматив хокукый актларны тормышка ашыруны тәэмин итү;
- ихтыяри ярдәмчеләрне (волонтерларны) исәпкә алуның бердәм базасын булдыру;
- шәһәрнең барлык ихтыяри ярдәмчеләр отрядлары һәм волонтерлары эшчәнлеген координацияләү;

- ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтендә катнашучыларны мотивацияләү һәм стимуллаштыру, иң яхшы ихтыяри ярдәмчеләрне (волонтерларны) бүләкләү методларын эшләү;
- ихтыяри ярдәмчеләр эшчәнлегенә оештыру-методик ярдәм күрсәтү;
- халыкның барлык яшь төркемнәренең – балалар, яшьләр һәм өлкән яшьтәге затларның ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашу мөмкинлекләрен киңәйтү;
- шәһәр халкы арасында ихтыяри ярдәмнең (волонтерлыкның) уңай имиджын булдыру.

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 нче ел мең сум | 2 нче ел мең сум | 3 нче ел мең сум | Барлыгы мең сум |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 500 | 500 | 500 | 1500 |
| Республика бюджеты | - | - | - | - |
| Федераль бюджет | - | - | - | - |

## 6 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

Тормышка ашыру механизмы түбәндәгеләрне күздә тота:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтен үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара совет төзү;

2) шәһәрнең ихтыяри ярдәмчеләр берләшмәләре чараларының бердәм ведомствоара планын раслау;

3) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучы ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләренең реестрын һәм рейтингын алып бару;

4) эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча яңа ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләре төзү;

5) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) юнәлешендәге чараларны оештыру;

6) волонтерлар отрядлары командирларыннан координация советы җыенын оештыру;

7) волонтерларны ихтыяри ярдәм (волонтерлык) юнәлешендәге чаралар оештыру методикасына өйрәтү;

8) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешмалар арасында партнерлык элемтәләрен җайга салу, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендә социаль инициативалар буенча тәҗрибә уртаклашу;

9) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) юнәлешендә яңа проектлар эшләү һәм гамәлгә кертү;

10) Яр Чаллы шәһәренең ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтенең торышы турында еллык аналитик хисап формалаштыру.

Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) өлкәсендәге эшчәнлекнең төрле юнәлешләрендәге ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлеген координацияләүне Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе гамәлгә ашыра.

Программа чараларын тормышка ашыру өчен башкаручылар, эшләрнең составы һәм эзлеклелеге, башкару сроклары һәм җаваплы затлар, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү буенча контроль чаралар билгеләнде (программага 1 нче кушымта, 2 нче кушымта).

Яр Чаллы шәһәрендә программаны тормышка ашыруга контрольне ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү буенча шәһәр ведомствоара советы гамәлгә ашыра. Ел саен кимендә ярты елга бер тапкыр совет утырышлары уза, аларда шәһәрдә ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтен оештыру һәм үстерү мәсьәләләре карала. Карап

тикшерелә торган мәсьәләләр буенча тиешле карарлар кабул ителә һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту башкарыла.

## 7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче индикаторлар

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Программа буенча ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп ителгән 7 яшьтән 70 яшькә кадәрге халык өлеше, әлеге яшь төркеменең гомуми саныннан:<br>2021 ел – 2 %<br>2022 ел – 3 %<br>2023 ел – 4 %<br>2024 ел – 5 %, | $C = \frac{C1 x 100\%}{C2}$<br><br>монда С1 – ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп ителгән халык саны;<br><br>С2 – 7 яшьтән 70 яшькә кадәрге халыкның гомуми саны (агымдагы елга статистика мәгълүматлары буенча) | Кварталлык аналитик хисаплар:<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;<br>Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге;<br>Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе;<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе;<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе;<br>Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе (алга таба – идарәләр) |
| 2. | Тормышка ашырыла торган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары, чаралар саны.<br>Программаны тормышка ашыру срогы дәвамында ел саен планлаштырыла торган күрсәткеч – үсеш узган ел белән чагыштырганда кимендә 3%. | $J = \frac{(J2-J1) x 100\%}{J1}$<br>монда J1 – узган ел дәвамында гамәлгә ашырыла торган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары саны<br>J2 – хисап (агымдагы) елында тормышка ашырыла торган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектларының саны | Идарәләрнең үткәрелгән ихтыяри ярдәм (волонтерлык) чаралары турында кварталлык аналитик хисаплары. |

## 8 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

2024 елга чараларны тормышка ашыру хисабына түбәндәгеләр планлаштырыла:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтен үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара совет төзергә.
2. Шәһәрнең ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләренең бердәм ведомствоара чаралар планын расларга.

3. Түбәндәгеләр базасында 2024 елга Яр Чаллы шәһәрендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) саны:

гомуми белем бирү оешмалары – кимендә 8500 ихтыяри ярдәмче (волонтер);

- Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге – кимендә 1000 ихтыяри ярдәмче (волонтер);

- һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары – кимендә 4000 ихтыяри ярдәмче (волонтер);

- яшьләр белән эшләү идарәсе учреждениеләре – кимендә 500 ихтыяри ярдәмчене (волонтерны) җәлеп итеп;

- мәдәният учреждениеләре – кимендә 400 ихтыяри ярдәмче (волонтер);

- физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре – кимендә 650 ихтыяри ярдәмче (волонтер);

- шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе – кимендә 200 ихтыяри ярдәмче (волонтер);

- архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү – кимендә 70 ихтыяри ярдәмче (волонтер);

- икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе – кимендә 2000 кеше.

4. Гражданнарны ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-коммуникация кампанияләренең санын арттыру.

5. Тормышка ашырыла торган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары, чаралары санын узган ел белән чагыштырганда ел саен кимендә 3% ка арттыру.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына
1 нче кушымта

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралары буенча финанслау

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткече | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел база | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2021 ел база | 2022 ел мең сум | 2023 ел мең сум | 2024 ел мең сум |
| Программаның максаты: милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, төрле яшьтәге гражданнарның массакүләм оештырылган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәтен үстерү. | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| 2024 елга программа буенча ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп ителгән 7 яшьтән 70 яшькә кадәрге халык өлеше, әлеге яшь төркеменең гомуми санының кимендә 5% | | | | | | 3 % | 4 % | 5 % | - | 500 | 500 | 500 |
| 2. Халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру | | | | | | | | | | | | |
| Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары конкурсы үткәрү | | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Чараларда катнашучылар саны, кеше. | | 30 | 30 | 30 | - | 80 | 80 | 80 |
| «Халыкка игелек» PR-проектын үткәрү (листовкалар, буклетлар әзерләү) | | Мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе; яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Басма материаллар саны, данә | | 400 | 400 | 400 | - | 20 | 20 | 20 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шәһәр проспектларында социаль банерлар әзерләп һәм урнаштырып, «Игелекле проект» социаль реклама конкурсы | Мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе; шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе; яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Банерлар саны, данә | 2 | 5 | 5 | 5 | - | 50 | 50 | 50 |
| Шәһәрнең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәте атрибутикасын (флаглар, курткалар, футболкалар) эшләү һәм әзерләү | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Атрибутика саны, данә | 36 | 400 | 250 | 250 | - | 120 | 80 | 80 |
| 3. Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү | | | | | | | | | | | |
| «Ихтыяри ярдәмчеләр мәктәбе» проектын тормышка ашыру | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | | 100 | 140 | 140 | - | 10 | 30 | 30 |
| Ел саен үткәрелә торган ихтыяри ярдәмчеләр форумы үткәрү | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше. | | 100 | 120 | 120 | - | 60 | 70 | 70 |
| «Елның ихтыяри ярдәмчесе» Бөтенроссия конкурсының муниципаль этабын оештыру | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше. | | 30 | 40 | 50 | - | 40 | 50 | 50 |
| 5 декабрьдә Бөтендөнья ихтыяри ярдәмчеләр көненә багышланган «Ихтыяри ярдәмчеләр көне» шәһәр чарасы үткәрү | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше. | | 300 | 400 | 400 | - | 90 | 90 | 90 |
| Ихтыяри ярдәмчеләрне транспорт грантлары белән тәэмин итү | Финанс идарәсе; яшьләр белән эшләү идарәсе | Ай саен | Транспорт грантлары саны, данә | - | 100 | 100 | 100 | - | 30 | 30 | 30 |
| | | | | | | | | барлыгы: | 500 | 500 | 500 |

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына
2 нче кушымта

## Программа чаралары

| т/б | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Программа чараларын башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Яр Чаллы шәһәрендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәтенең норматив-хокукый базасын һәм инфраструктурасын үстерү | | | | |
| 1.1. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтен үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара совет төзү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | яшьләр белән эшләү идарәсе | Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшен координацияләү һәм аларга булышлык итү өчен профильле ведомстволар арасында җаваплылыкны бүлү |
| 1.2. | Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) чараларының бердәм ведомствоара планын раслау | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе;<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе;<br>Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>халык иминлеген тәэмин итү бүлеге;<br>икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе<br>(алга таба – Башкарма комитет идарәләре) | Ведомствоара план нигезендә кимендә 50 чара үткәрү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.3. | Шәһәрнең белем бирү оешмалары, коммерцияле булмаган оешмалар, оешмалар базасында ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре төзү һәм аларның эшчәнлеге | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитет идарәләре | Төрле идарә һәм ведомстволар базасында ихтыяри ярдәмнең (волонтерлыкның) барлык юнәлешләре буенча яңа отрядлар төзү:<br>- мәгариф идарәсе – мәгариф өлкәсендә, гражданлык-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр отрядлары, сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикле ихтыяри ярдәмчеләр отрядлары (инклюзив ихтыяри ярдәм), табигатьне саклау һәм экологик агарту өлкәсендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык), медиаволонтерлык;<br>- физик культура һәм спорт идарәсе – спорт өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр, вакыйгалар волонтерлыгы (зур, әһәмиятле вакыйгалар һәм чаралар);<br>- мәдәният идарәсе – мәдәният өлкәсендә ихтыяри ярдәм;<br>- шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе – территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр, экология һәм табигатьне саклау өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр;<br>- архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе – шәһәр мохитен һәм туристлык эшчәнлеген үстерү өлкәсендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык) ;<br>- халык иминлеген тәэмин итү бүлеге – Эчке эшләр органнарына ярдәм күрсәтү өлкәсендә ихтыяри ярдәм (волонтерлык), гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә ихтыяри ярдәмчеләр. |
| 1.4 | Ихтыяри ярдәм берләшмәләрнең эш регламентын эшләү һәм ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтен үстерү өчен җаваплыны билгеләү (юл картасы) | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитет идарәләре | |
| 1.5 | Ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү буенча аналитик хисап бирү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитет идарәләре | Ярты еллык хисаплар һәм аналитик еллык хисап тапшыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. Халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру | | | | |
| 2.1 | Ихтыяри ярдәмнең (волонтерлыкның) төрле юнәлешләре буенча ачык лекторийлар оештыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитет идарәләре | Ел саен кимендә 10 ачык лекторий үткәрү |
| 2.2 | Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) чараларын яктырту өчен шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларын (телевидение, радио, газеталар һ. б.) җәлеп итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитет идарәләре | Ел саен шәһәрнең рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында кимендә бастырып чыгарылган 50 мәкалә |
| 2.3 | Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) чараларында катнашучыларга рәхмәт хатлары җибәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитет идарәләре | Ел саен |
| 2.4 | Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) өчен Башкарма комитет карамагындагы учреждениеләр тарафыннан оештырыла торган мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларына чакыру билетлары бирү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>мәгариф идарәсе;<br>физик культура һәм спорт идарәсе;<br>мәдәният идарәсе | Ел саен |
| 3. Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү | | | | |
| 3.1. | Махсус шартлар белән бәйле эшчәнлектә катнашучы ихтыяри ярдәмчеләргә (волонтерларга) психологик ярдәм оештыру һәм күрсәтү һәм психологик реабилитацияләүдә булышлык итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | яшьләр белән эшләү идарәсе | Кимендә 10 төркемле консультация үткәрелде. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3.2 | Өстәмә белем бирү учреждениеләре базасында ихтыяри ярдәмчеләрне (волонтерларны) укытуга юнәлдерелгән өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруны оештыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | мәгариф идарәсе | Кимендә 1000 бала һәм яшүсмер катнашында кимендә 15 дәрес үткәрелде |
| 3.3. | Үз эшчәнлеге юнәлеше буенча ихтыяри ярдәмчеләрнең (волонтерларның) массакүләм шәһәр, республика, Бөтенроссия чараларында катнашуын тәэмин итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитет идарәләре | Үз эшчәнлеге юнәлеше буенча ихтыяри ярдәмчеләрнең (волонтерларның) шәһәр, республика, Бөтенроссия чараларында катнашуы. |